СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2021 г. Заинск № 78

**«Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Хезмәт өчен түләүнең Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының «Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы карары белән расланган (2016 елның 27 августындагы 194 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.7 пунктта «, компенсация һәм персонифицирланган адаптация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Җирле үзидарә органнары эшчеләренә билгеләргә:

1) айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) еллык түләүле отпуск биргәндә айлык тариф ставкасының 120 проценты күләмендә матди ярдәм күрсәтү.

Календарь ел дәвамында эшчегә еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, еллык түләүле отпуск бирелгәндә матди ярдәм исәпләнә һәм аңа декабрьдә эшләнгән эшләргә пропорциональ рәвештә түләнә, эштән киткән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

Еллык түләүле отпускны эшче эшләгән беренче елда биргәндә матди ярдәм календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә.

4) һөнәрләрне бергә алып барган, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйгән һәм төп вазыйфа белән беррәттән вакытлыча булмаган эшчеләрнең эшен алып барган өчен айлык өстәмә түләү - гамәлдәге законнар нигезендә хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә төп эш буенча айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә.

төнлә эшләгән өчен (22 сәгатьтән 06 сәгатькә кадәр) - бердәм тариф челтәре (ЕТС) нигезендә, барлык билгеләнгән өстәмәләрне исәпкә алып, бер сәгать тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен - ЕТС нигезендә билгеләнгән барлык өстәмәләрне исәпкә алып, икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

хезмәт урыны җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен - айлык тариф ставкасының 2,5 проценты күләмендә;

хезмәт урыны җиңел автомобильләре йөртүчеләренә авариясез эш режимы өчен - айлык тариф ставкасының 20 проценты күләмендә.

5) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм.

2. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**